ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СОБОЛЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
СОБОЛЕВСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ    КАРАР

28.03.2017    с. Соболевсое    № 8

Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативларын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.4 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге халкының җирле әһәмияттәге объектлар белән тәэмин ителешнең исәп-хисап күрсәткечләрен һәм Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге халкы өчен мондый объектларның максималь рөхсәт ителгән территориаль дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләрен үз эченә алган Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектлау нормативларын әзерләргә.

2. Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлегенең башкарма комитетын Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектларының җирле нормативлары проектын әзерләү өчен җаваплы итеп билгеләргә.

3. Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлегендә муниципаль контракт төзелгәннән соң бер ай эчендә шәһәр төзелеше проектларының җирле нормативларын эшләү вакытын билгеләргә.

4. Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлеге шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары проектын эшләүгә техник йөкләмәне Кушымта нигезендә расларга.

5. Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге башкарма комитеты секретарена Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектлары буенча җирле нормативлар проектын әзерләү буенча тәкъдимнәр җыюны һәм гомумиләштерүне тәэмин итәргә.

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы    О. Н. Майорова

Соболевский авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2017елның 28 мартыннан №8 карарына
Кушымта

«Соболевский авыл җирлегенең шәһәр төзелеше проектларының җирле нормативлары проектын эшләү» темасы буенча эшне башкаруга
ТЕХНИК БИРЕМ

| т/б № | Мәгълүматлар һәм таләпләр исемлеге | Мәгълүматларның һәм таләпләрнең эчтәлеге |
|---|---|---|
| | 2 | 3 |
| | Фәнни-техник продукция төре | Соболевский авыл җирлеге шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары |
| | Заказ бирүче | Соболевский авыл җирлеге башкарма комитеты |
| | Башкаручы | ... килешү буенча билгеләнә (алга таба - Башкаручы) |
| | Фәнни-тикшеренү эшен башкару өчен нигез | Соболевский авыл җирлеген шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары проектын эшли башлау турында Соболевский авыл җирлеге башкарма комитеты карары |
| | Тикшеренү объекты, аның төп характеристикалары | Соболевский авыл җирлеге территориясе |
| | Эшнең максаты | Авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге объектларының түбәндәге өлкәләргә карый торган минималь мөмкин булган дәрәҗәдә исәп-хисап күрсәткечләре җыелмасын билгеләү:<br>халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, су агызу, җирле әһәмияттәге автомобиль юллары, физик культура һәм массакүләм спорт, мәгариф, сәламәтлек саклау, эшкәртү, утильләштерү, каты коммуналь калдыкларны зарарсызландыру, урнаштыру, җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итүгә, территорияне төзекләндерү объектларына, җирлекнең җирле әһәмиятендәге башка объектларга бәйле рәвештә башка өлкәләр.<br>Авыл җирлеге халкы өчен мондый объектларның территориаль яктан мөмкин кадәр күбрәк файдалана алуының исәп-хисап күрсәткечләрен билгеләү. |
| | Эшләр башкаруның норматив-хокукый базасы | 1.Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы ФЗ-190, 29.12.2004 ел<br>2.«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль |

| т/б № | Мәгълүматлар һәм таләпләр исемлеге | Мәгълүматларның һәм таләпләрнең эчтәлеге |
|---|---|---|
| | 2 | 3 |
| | | закон<br>3.«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы<br>4.СП 42.13330.2011«Шәһәр төзелеше. Шәһәр һәм авыл җирлекләрен планлаштыру һәм төзү»<br>5.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 27 декабрендәге 1071 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы шәһәр төзелешен проектлауның республика нормативлары.<br>6.Югары Ослан муниципаль районының «Шәһәр төзелешен проектлауның җирле нормативлары».<br>7.Башка норматив хокукый актлар һәм норматив техник документлар |
| | Эшне башкару өчен башлангыч мәгълүматлар | Эшләрне башкару өчен кирәкле башлангыч мәгълүматлар исемлеге башкаручы заказчы белән килештереп формалаша, оригиналь мәгълүматны җыю заказ бирүче ярдәмендә башкаручыда башкарыла |
| | Тапшырыла торган материалларның составы һәм эчтәлеге | Авыл җирлеген шәһәр төзелешен проектлау нормативлары проекты составы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 29.2 статьясындагы 5 өлеше нигезләмәләренә туры килергә һәм түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:<br>төп өлеш (авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге объектлары белән тәэмин ителешнең минималь рөхсәт ителгән дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре һәм мондый объектларның авыл җирлеге халкы өчен максималь рөхсәт ителә торган дәрәҗәсенең исәп-хисап күрсәткечләре);<br>шәһәр төзелешен проектлау нормативларының төп өлешендәге исәп-хисап күрсәткечләрен нигезләү материаллары;<br>шәһәр төзелешен проектлау нормативларының төп өлешендә булган исәп-хисап күрсәткечләрен куллану кагыйдәләре һәм өлкәсе.<br>Авыл җирлеген шәһәр төзелешен проектлау нормативларын әзерләү түбәндәгеләрне исәпкә алып башкарылырга тиеш:<br>1) муниципаль берәмлек территориясендә халыкның социаль-демографик составы һәм тыгызлыгы;<br>2) муниципаль берәмлекнең комплекслы социаль-икътисадый үсеше планнары һәм программалары; |

| т/б № | Мәгълүматлар һәм таләпләр исемлеге | Мәгълүматларның һәм таләпләрнең эчтәлеге |
|---|---|---|
| | 2 | 3 |
| | | 3) җирле үзидарә органнарының һәм кызыксынган затларның тәкъдимнәрен. |
| | Эш нәтиҗәләрен килештерү | Башкаручы эш нәтиҗәләрен килештерү барышында заказчы тарафыннан алынган искәрмәләргә һәм тәкъдимнәргә җавап бирә, кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алуның яисә кире кагуның нигезле нигезләмәләрен әзерли, эш нәтиҗәләренә төзәтмәләр кертә |
| | Тапшырыла торган материалларның формасы | Материалларны тапшырырга:<br>- кәгазь чыганакларда А4 форматында - 2 экз .<br>Эш нәтиҗәләренең электрон версияләре башкаручы тарафыннан заказчы белән килешенгән мәгълүматтан DOC( DOCX, RTF) форматында бирелә. |

Югары Ослан муниципаль районы
Соболевский авыл җирлеге башлыгы О.Н.Майорова